Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Пановка авыл җирлеге башкарма комитеты

# КАРАР

27 июль, 2022 № 11

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Пановка авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарын бәяләүгә гомуми таләпләргә үзгәрешләр кертү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 15 июнендәге 1081 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Пановка авыл җирлеге башкарма комитеты карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Пановка авыл җирлегенең 2021 елның 26 июлендәге 15 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Пановка авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 Тәртипнең 1 бүлегенең 3 пунктында «муниципаль программаларның структур элементлары» сүзләрен төшереп калдырырга.

1.2 Тәртипнең III бүлегенең 12 пунктына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- икенче абзацта «, муниципаль программаларның структур элементларына» сүзләрен төшереп калдырырга;
- өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ташламаларга түләүчеләр тарафыннан бирелгән ташламаларга ихтыяҗ булу, ул ташламаларга хокуктан файдаланучы түләүчеләр санының һәм ташламалар куллануга потенциаль хокукка ия түләүчеләр санының 5 еллык чорга нисбәте белән характерлана.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында http://www.pestreci.tatarstan.ru, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда http://pravo.tatarstan.ru Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Пановка авыл җирлеге башлыгы О.И. Козырев